РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА
БЮРГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 октябрь 2025 ел

№ 4

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Боерган авыл җирлегенең
Чуаш Сарыкамышы торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган авыл җирлеге Уставының 11 һәм 22 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге башлыгы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елның 03 ноябренә 11.00 сәгатьтә Иске Борындык авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган авыл җирлегенең Чуаш Сарыкамышы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Боерган авыл җирлегенең Чуаш Сарыкамышы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эш төрләрен башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- җирле әһәмияттәге торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( юлларны ремонтлау);

- Чуаш Сарыкамышы авылында торак пункт территориясен төзекләндерү ( кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, эш һәм килешү буенча хезмәт күрсәтү өчен түләү)?».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Боерган авыл җирлеге башлыгы И.В.Малышева